


Пенза шәһәрендә Халыкара «Татар кызы – 2024» бәйгесенен финалы узды. «Татар кызы – 2024» исеменә Оренбургтан Алсу Байгильдина лаек булды. Таж белән бергә кыз автомобиль ачкычларын алды. Жинvчегә аларны Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары, Ботендонья татар конгрессы Милли советы рәисе Васил Шәйхразиев тапшырды.
Ярышнын топ максаты - татар халкынын милли мәдәниятен, гореф-гадәтләрен һәм телен торгызу, саклау һәм vстерv, яшь буын вәкилләренә рухи мирасны тапшыру. Казанда узган ярымфиналда кызлар матурлык һәм талант буенча гына тvгел, ой эшләрен алып бару һәм татар милли мәдәниятен белv буенча да коч сынаштылар.       Ә Пензада конкурснын финал олеше vтте. Конкурсантлар хәлиткеч этап программасында vзенне тәкъдир итv, театральләштерелгән куелышта чыгыш ясау, ыру агачы турында хикәя һәм ыру ядкарьләрен тәкъдим итv иде.
Матурлык, акыл һәм талант бәйрәменен финалына 12 чибәр кыз чыккан. Алар арасында тамырлары буенча якташыбыз Ленинград олкәсеннән Юсупова Диляра. Тагы Батыркаева Ангелина – Пермьнән, Бәдриева Фәизә – Мәскәvдән, Байгильдина Алсу – Оренбургтан, Габдуллина Энже – Татарстаннан, Галиveева Асия – Кыргызстаннан, Дәvләтшина Алсу – Башкортстаннан, Закирова Ленара – Үзбәкстаннан, Мәхмvтова Фәрзәнә – Самарадан, Нәсретдинова Вәсилә – Казахстаннан, Сәйфуллина Алсу – Пензадан, Сәйдуллина Лилия – Томәннән. Шулай ук, ике кыз – Ростовтан Юлия Бараева белән Кировтан Илнара Әхәтова махсус призга лаек булып, «Татар кызы-2024» титулы очен коч сынашмыйча гына, финал бәйгесендә катнашу хокукына ия булган иде.
«Татар кызы – 2024» бәйгесе финалында Ленинград олкәсеннән «Файда» татар мәдәни жәмгыятенен яшьләр белән эшләv кураторы Диляра Юсупова чыгыш ясады. Әлеге ярышта Диляра «Ин сойкемле кыз» титулына ия булды; тырышлык нәтижәсе. Анын девизы да «Сабырлык - унышка ачкыч». Язма героебыз тумышы белән

Санкт-Петербургтан булса да, vзенен икенче Ватанын Мордовиянен Зубово-Поляна районы Кочетовка-Чатока авылын саный. Әйтеп китәргә кирәк, Диляранын әнисе - Рушания Акрям кызы, Чатокада туып vскән. Диляра биш ел буе «Файда» исемдәге татар фольклор ансамблендә жырлый һәм бии. Буш вакытында фотога һәм видеога тошерергә ярата. 2018 елда ул «Кочетовка» сайтын булдыра һәм анда авыл тормышы, халкы турында яза; шул авыл белән элемтәсе тыгыз. Без, анын Мордовия дуслары, конкурста жинvен теләдек, ихластан жан аттык.
Гаилә елында конкурснын топ темасы – гаилә кыйммәтләре аша халыкнын мәдәниятен саклау. Финалда катнашучыларнын һәрберсенә vзен театральләштерелгән спектакльдә чыгыш ясап, ыру агачы турында сойләргә һәм гаилә истәлеген тәкъдим итәргә тиеш иделәр. Диляра Юсупова Кочетовка авылындагы карт әбисе Арифә Аббяс кызы Немешеванын һәм  карт әбисенен кызы - Халидә Хусяин кызы Маминанын тамбур чигелеше белән чигелгән солгесе турында сойләгән бу конкурста. Мәдәният саклаучы гаилә башы, Диляранын бабасы - Абубекир улы Акрям Маминнын, оныгынын милли тәрбиясенә керткән олеше байтак. Шуна да интервьюсында татар хатын-кызына хас жавап алынды.
«Минем очен бу тормышта ин моһиме – гаилә. Мин vземнен зур тату гаиләм булуын бик телим, шуна кvрә мин эш хакына шәхси тормышымны корбан итәргә әзер тvгел»,- дип жавап бирде әнгәмәсендә Диляра.
Киләсе елда «Татар кызы» 12 нче халыкара конкурсынын финалы Оренбургта узачак.

**Наилә НАСЫРОВА**